ИСПОЛНИТЕЛЬНО О КОМИТЕТА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ГОРОД БАВЛЫ» РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ” МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ БОЕРЫК

11.08.2022 Баулы ш. №71

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2020 елның 31 мартындагы 50 номерлы карары белән расланган «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 15 июнендәге «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» 1081 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2020 елның 31 мартындагы 50 номерлы карары белән расланган «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта «муниципаль программаларның структур элементлары» сүзләрен төшереп калдырырга;

12 пунктның икенче абзацында «муниципаль программаларның структур элементларына» сүзләрен төшереп калдырырга;

12 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бирелгән ташламаларга ихтыяҗ булу, ул ул ташламаларга хокуктан файдаланучы түләүчеләр санының ташламалардан файдалану хокукына ия түләүчеләр санының 5 еллык чорга нисбәте белән характерлана.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында сайтта (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

«Баулы шәһәре» муниципаль
берәмлеге Башкарма комитеты
җитәкчесе Д.Л. Бакиров